*Габидуллина Э.И. (КИУ, Казань)*

# ВӘГАЗЬ ТЕКСТЛАРЫНДА ГАРӘП-ФАРСЫ АЛЫНМАЛАРЫ

**Аннотация:** В данной статье описаны особенности текста вагаза (проповеди) как религиозного текста, используемого в целях воспитания нравственности, духовности населения. В названных текстах широко используются арабо-персидские заимствования, так как исламская религия основана на учениях Корана. В статье приводятся отличительные признаки арабских и персидских заимствований, рассматриваются их наиболее часто встречающиеся элементы в текстах вагазов.

**Ключевые слова:** вагаз (проповедь), текст, арабско-персидские заимствования, словообразовательные признаки.

**The Arab-Persian borrowings in the text of sermons**

**Abstract:** This article describes the features of vagaz (sermons) as a religious text used to promote morality and spirituality of the population. Arab-Persian borrowings are widely used in these texts, as the Islamic religion based on the teachings of the Koran. The article presents distinctive features of Arabic and Persian borrowings, considers their most common elements in the texts of sermons.

**Key words:** vagaz (sermon), text, Arabic-Persian borrowings, derivational characteristics.

Вәгазь ул – үгет-нәсыйхәт, өйрәтү дигәнне аңлата. Вәгазь тик дин һәм дини йолаларга кагылышлы мәсъәләләрне генә як-

тыртырга тиеш. Шул уңайдан вәгазьдә әдәп, әхлак, мөселманнарның үз-үзләрен тоту кагыйдәләре турында сөйләнә.

Оста вә гүзәл итеп сөйләнгән вәгазь халыклар йөрәгенә гайрәт кертә, аларны шатландыра, елата, үкендерә, дәртләндерә, яшен-картын берләштерә. Бер фикергә хезмәт итәргә, бер максатка юнәлергә өнди. Аларга бертөрле хис, бертөрле юнәлеш бирә. Вәгазьнең кыйммәтен вә әһәмиятен сүз белән генә әйтеп бетерерлек түгел. Шуңа күрә дә инсаннарның барчасы тереклекләрендә рухлана алган һәртөрле мәгълүматлары – гүзәл сөйләүче хатыйбларның нотык вә вәгазьләреннән хасил булган рух дисәк тә хата булмас. Вәгазьдә сүз сәнгатенә төшенүне, аны аңлау мизгелен ике яклы күренеш итеп карарга кирәк. Беренче: сүз тыңлаучыларның уен, хисен тәгаен билгеләргә, тыңлаучыларның аңына тәэсир итәргә тиеш. Вәгазьдә иң әһәмиятле сүзнең, кайда урнашуына карап, билгеле хис дулкынына исәпләнгән аһәңе барлыкка килә [3, с. 7].

Вәгазь текстында туры мәгънәдә кулланылмаган сүзләр, башка телдән кергән сүзләр, төрле атамалар кергән сөйләм, читләтеп әйтергә теләгән фикерләр, астыртын көлү, мыскыллау һ.б. куштырнаклар белән аерымланалар.

Вәгазьләрдә Исламның тоткан урыны, уңышлары, бүгенге көннең аеруча җитди мәъләләре хакында әңгәмәләр дин гыйлемен өйрәнергә теләүче һәркем өчен белем чыганагы дип санала.

Дини вәгазьләрнең максаты – укучының дини хис уятып, халыкка дини тәрбия бирү, аларны рухландыру.

Халыкның гореф-гадәте тәрбия нигезендә барлыкка килгән. Тәрбия дигәндә, без дини тәрбияне күз алдында тотабыз. Шуңа күрә без үз-үзебезне тотышыбызда, сөйләшүебездә һәм көнкүрешебездә, тормышыбызда дини тәрбиянең чагылышын таба алабыз.

Татар галимнәре, мәгърифәтчеләре, дин әһелләре җәмгыятьтәге сыйнфый тигезсезлекне, җәбер-золымны һәр кешегә аң-белем, яхшы тәрбия бирү юлы белән бетерергә мөмкин дип карыйлар. Нәтиҗәдә фәнни-фәлсәфи фикер барлыкка килә, илаһият гыйлеменә кагылышлы хезмәтләр, фәлсәфи трактатлар, әхлакый вәгазьләр, матур әдәбият әсәрләре иҗат итела башлый.

Тел барлык этапларында да җәмгыять белән аерылгысыз бәйләнештә торган. Тел – кешеләр аралашуында иң әһәмиятле чара. Тел җәмгыятькә бәйле һәм,

җәмгыять үсешен алга алып бару өчен, зур урын тотып тора.

Татар халкының гасырлар дәвамында башка төрки һәм төрки булмаган халыклар белән сәяси, матди, рухи бәйләнештә булуы татар теленең лексик системасында да чагылыш тапкан. Шушы матди-рухи мөнәсәбәтләр нәтиҗәсе буларак, телебездә чит телләрдән кергән сүзләр актив кулланыла башлый. Аеруча ислам дине тәэсирендә гарәп теленнән кергән лексик берәмлекләрнең актив булуын истә тотырга кирәк. Гарәп сүзләре зур роль уйный һәм бүген дә сан ягыннан алар күпчелекне тәшкил итә. Гомумән, урта гасырларда тулысынча формалашып беткән гарәп сүзләре күп кенә илләрдә сүзлек составында төп нигез ролен үти. Ислам диненә кагылган сүзләр һәм гарәп теленнән кергән сүзләр таралуы нәтиҗәсендә, төрки халыкларның системасы тамырдан үзгәрә, гарәп сүзләренә, дини терминнарга байый [5, с. 10].

Татар телендә саны һәм активлыгы белән гарәп, фарсы һәм рус алынмалары аерылып тора. Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән алынмалар хәзерге телебездә дә бик күп санлы; ә борынгырак чорда, бигрәк тә XVII-XVIII гасырларда, алар тагын да күбрәк булганнар. Бу алынмалар Болгарда ислам дине кабул ителгәннән соң, сәүдә, дин, сәясәт, мәдәният, әдәбият-сәнгать бәйләнешләре аша килеп кергәннәр [2, с. 58].

Кайбер алынмалар телебездә ныклап урнашып калганнар, татарлашканнар, яңа сүзләр ясау өчен нигез булып хезмәт итә башлаганнар. Әйтик, гарәп теленнән кергән тәртип, Ватан, хат, рәсем, сабыр һ.б. сүзләр хәзерге көндә дә кулланыла.

Гарәп һәм фарсы теленнән кергән алынмаларның аермалы билгеләре бар. Гарәп теле хәмид-сәмид телләре группасына, ә фарсы теле һинд-иран телләре группасына карый. Фарсы теленең татар теленә йогынтысы болгар чорыннан ук башланса да, тәэсир көче гарәпнекенә караганда кимрәк. Фарсы алынмалары 10-12 % тәшкил итә [7, с. 5].

Гарәп теле билгеләре:

1) гарәп телендә [г], [п], [ч] тартыклары юк, алар урынына [ж], [б], [ш] тартыклары туры килә. Шуңа күрә бер үк мәгънәле сүзләр ике яңгыраштa йөри: Гәүһәр – Җәүһәр.

2) сүз уртасында кистереп әйтү: тәэсир, мәсьәлә, тәкъдим.

3) сүз башында [р] тартыгы булган сүзләрнең күбесе: рөхсәт, рәхим.

4) -а/-ә, -ат/-әт, -ият исем кушымчалары ялганган сүзләр:

әдәбият, сәясәт, рисалә, хорафат.

5) исем алдыннан мы-, мө-, мә-, тә-, кушымчалары килү: мәктәп, тәртип, мөселман, тәвәккәл.

6) -ый/-и сыйфат кушымчалары алган сүзләр: хәрби, сыйнфый, фәнни.

7) икеләтелгән тамырдан торган сүзләр: зилзилә, зәмзәм, дөлдөл.

Фарсы теле билгеләре:

1) -стан компоненты: Татарстан, Казахстан;

2) -дар компоненты: хәбәрдар, хөкемдар;

3) -гир компоненты: җиһангир;

4) -гәр компоненты: сәүдәгәр;

5) -кяр компоненты: фидакарь;

6) -намә (язу дигәнне аңлата) компоненты: рөхсәтнамә (лицензия);

7) -ханә (өй дигәнне аңлата) компоненты: даруханә;

8) на– алкушымчасы: нахак, надан, нарасый;

9) би– алкушымчасы: бихисап, бинисап, бимаза, бичара. [7, с. 5]

Телнең үсеше турында сөйләгәндә, лексикадагы үзгәрешләргә күбрәк игътибар итәлә. Беренче карашка телнең үсешен аның лексик материалы нигезендә күзәтү барыннан да җиңел кебек. Кешелекнең матди һәм рухи тормышы теләсә кайсы телнең сүзлек составында чагылыш табарга мөмкин. Бер төркем сүзләр искерә, онытыла, бөтенләй кулланылмый башлый, икенче төркем сүзләр, киресенчә, яңадан ясала, телне баета, аның кулланылышы да арта.

Сүзлекләр татар теленең бердәм лексик нормалары эшләнүнең озын һәм дәвамлы процессын ачык күрсәтеп торалар. Татар әдәби теленең төп лексикасын, билгеле бер күләмдә архаизмнар, тарихи сүзләр, терминнар һәм лексик диалектизмнар татар теле белеменә дә зур өлеш кертәләр. Әлеге хезмәтләр татар теленең лексикасын фәнни яктан өйрәнү өчен ышанычлы чыганак булып торалар.

Бер генә телнең дә сүзлек байлыгы кинәт кенә, берьюлы барлыкка килмәгән. Ул озын, тарихи юл үткән, күп еллар дәвамында үскән, формалашкан. Гасырлар дәвамында яңа сүзләр барлыкка килгән, аларның мәгънәләре дә киңәя барган. Бу процесс халыкның сәяси, икътисадый һәм мәдәни тормышы белән бәйләнештә барган. Татар теленең лексик байлыгы зур үсеш алган һәм башка телләрдән берничек тә калышмый. Анда төрле структураларга һәм стильләргә караган йөзләрчә мең сүзләр бар [4, б. 3].

Яңа сүзләр барлыкка килү яңа күренеш, төшенчәләр, техника һәм мәдәниятнең, ке-

шелек белемнәренең артуы һәм киңәюе белән аерылгысыз бәйләнештә булса да, барлыкка килгән һәм кулланылыштан чыккан берәмлекләр саны, алда әйтелгән сәбәпләр аркасында мәгънәләрен үзгәрткән лексемалар җирлегендә алай ук күп түгел. Еш кына бер мәгънәле сүз, яңа мәгънәләр белән тулыланып, полисемантик сүзгә әйләнә. Лексиканың камилләшүе сүзлек байлыгының сан ягыннан артуына гына кайтып калмый, лексиканың сыйфат ягыннан үсүе дә зур әһәмияткә ия. Әлегә кадәр гамәлдә булган сүзләрнең мәгънәләре арту телнең сыйфаты үсүен күрсәтә. Татар телендә күптәннән кулланыла торган сүзләрнең яңа мәгънәләре көндәлек тормыштагы, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә һәм фән-техниканың алга китүенә бәйле рәвештә үсеп чыга. Мондый мәгънәләрне икегә бүлеп карау уңайлы:

1) көнкүрештәге һәм җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйләнгән мәгънә үзгәрешләре;

2) гадәти сүзләрне терминлаштыру нәтиҗәсендә туган өстәмә мәгънәләр.

Мәсәлән: баскыч – 1) лестница; ступень, ступенька, трап; подножка, стремянка; 2) давило; бөят – 1) подхомутник, хомутина; 2) спасательный пробковый круг; күләгә – 1) тень, сень; зонтик; япкыч – покрывало; покрышка; ярлык – 1) ярлык; 2) квитанция, расписка, письменный пропуск; 3) указ, царская грамота, диплом һ.б. [4, с. 3].

Татар әдәби теленә кергән гарәп-фарсы сөйләм телендә һәм әдәби әсәрләрдә генә кулланылып калмый, вәгазьхөтбәләрдә дә күрергә мөмкин. Татар телендә гарәп сүзләрен төрләргә бүләргә мөмкин:

1. Дини эчтәлекле сүзләр, дини терминнар: Аллах, Илаһи, нәби, дин, иман, гыйбадәт, фарыз, сөннәт, хаҗ, корбан, җәһәннәм, тәсбих һ.б.

2. Уку-укыту эшләренә караган сүзләр: кыйраәт, инша, имля, мөгаллим, мәктәп, мәдрәсә, дәрес, имтихан.

3. Фән һәм матбугат өлкәсенә караган сүзләр: һәндәсә, табигать, фикер, мантыйк, сарыф, наху, әдәбият, хисап, матбугат, мөхәррир.

4. Иҗтимагый-политик терминнар: иҗтимагый, мәмләкәт, икътисади, сәясәт, казый, дәүләт, идарә, хөкем.

5. Тормыш– көнкүреш лексикасы: шулпа, шикәр, гаилә, нәсел, кабилә, халык, бина, бәет, кәлимә, сандык, хат, мәхәббәт һ.б.

6. Хәрби һәм медицина теминнары: хәрби, баруд (порох), гаскәр,тыйбб (медицина), табиб, дәва, шифа һ.б.

7. Абстракт төченчәләр белдерүче сүзләр: ихтыяр, мөнәсәбәт, игътибар, мәгълүм,

инсаниять, рухиять һ.б. сүзләр.

8. Кеше исемнәре: Габдулла, Габдрахман, Әхмәт, Кәрим, Хәсән, Зәки, Газизә, Әминә, Сабира һ.б. исемнәр [2, с. 798].

Әлеге мәкаләбездә вәгазь текстларында кулланылган гарәп-фарсы алынмаларына игътибар итәргә булдык. Моның өчен без Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдиннең «Бәхетлеләрнең серләре» бишенче китапка [6] мөрәҗәгать иттек. Әлеге җыентыкка егерме алты вәгазь тупланган. Шул вәгазь өзекләрләреннән гәрап-фарсы алынмаларына тукталабыз.

«Сихерче һәм изге кеше» вәгазеннән өзек:

Пәйгамбәребез (с.г.в) сөйләгән әлеге кыйссаны безгә Сухаеб җиткерә. Элеккеге заманнарда бер патша яшәгән. Аның бер сихерчесе булган. Ул олайгач, патшага:

- Сихер белемен өйрәтеп калдырыр өчен миңа яшь бер егет юлла, – дигән [6, б.20].

Пәйгамбәр «пророк» – фарсы сүзе (пәйгамбәр) «пәйгамбәр» сүзеннән.

Кыйсса « рассказ, поэма» – гарәп сүзе (касс) «ни булганны судта сөйләү» асылда латин. casus «казус, суд, очрак» сүзеннән килә.

Патша « царь, падишах» – фарсы сүзе (падшаһ) «тәхеттәге шаһ» (пад, пати «тәхет», шаһ «шаһ») сүзеннән.

Заманә ис. Заман – гарәп сүзе (заман) сүзеннән.

«Кешене Җәннәткә алып кергән эт» вәгазеннән өзек.

Үзен эт урынына куеп ярдәм кулын сузган кеше барыбыз өчен дә үрнәк. Үзе өчен генә яшәп, башка җан ияләренең хәленә керә белмәгән кеше, чын мәгънәсендә, кеше дип аталырга лаек түгел [6, с. 36].

Җан «душа» – фарсы сүзе (җан) «җан, энергия, тын, сулыш» бор.ирани.dah, dayah «тын, сулыш, һава» сүзеннән.

«Бурычка акча биреп торуның әҗере» вәгазенән өзек:

Аллаһы Тәгалә: «Әй бәндәм, намаз, ураза, хаҗ, корбан – болар Минем боерыкларым иде», дип җавап бирә.

Намаз «намаз, молитва» – фарсы сүзе (намаз) «намаз» сүзеннән. Намаз гамәле ислам диненә ирани халыклардан кергән.

Корбан «җертва» – гарәп сүзе (курбан-үн) «корбан» сүзеннән.

Мәгънә «значение, смысл, сущность, суть» – гарәп сүзе (мәгънә) «аңлашылган нәрсә; мәгънә, фикер, идея» сүзеннән.

«Йөз кешене үтергән бәндә» вәгазеннән өзек:

Иң мөһиме – гөнаһлардан тәүбә иткәннән соң аларны кабат эшләмәс өчен бөтен көчеңне куярга кирәк. Әгәр дә бүген тәүбә итсәң, иртәгә шул

ук гөнаһны эшләсәң, андый тәүбә тукран тәүбәсе булып санала һәм андый тәүбәләр кабул ителмәячәк [6, с. 17].

Гөнаһ «грех» – фарсы сүзе (гүнаһ) «бурыч, гаеп, җинаять» сүзеннән. Тамыры бор.иран nā «гаеп, явызлык, хата,ялгыш».

Тәүбә «раскаяние, покаяние» – гарәп сүзе (тәүбә-т-үн) «тәүбә» сүзеннән. Шуннан ук чув. тупа, удм. тубо «тәүбә, ант».

«Тау куышында калган өч юлчы» вәгазеннән өзек:

Бу кыйссада өч төрле игелек искә алына: беренчесе – ата-анага карата булган игелек, икенчесе – зинадан тыелу, өченчесе – сакчылыкка калдырган әманәтне иң күркәм рәвештә саклау [6, с. 13].

Әмәнәт «залог, заложник, страхование» – гарәп сүзе (амәнәт-үн) «ышаныч, ышанып тапшырылган нәрсә» сүзеннән.

Кыйсса « рассказ, поэма» – гарәп сүзе (касс) «ни булганны судта сөйләү» асылда латин. casus « казус, суд, очрак» сүзеннән килә.

«Аллаһ теләсә, дип әйт» вәгазеннән өзек:

Сөләйман пәйгамбәр үз заманында дөнья күләмендә танылган бер патша иде. Аллаһы Тәгалә кешеләрне, җеннәрне, хайваннарны һәм җил-давылларны, гомумән, табигатьне аңа буйсындырган иде [6, с. 92].

Пәйгамбәр «пророк» – фарсы сүзе (пәйгамбәр) «пәйгамбәр» сүзеннән.

Заманә ис. Заман – гарәп сүзе (заман) сүзеннән.

Патша «царь, падишах» – фарсы сүзе (падшаһ) «тәхеттәге шаһ» (пад, пати «тәхет», шаһ «шаһ») сүзеннән.

Җен миф. «бес, черт» – гарәп сүзе (җинн) сүзеннән.

Табигать «природа, натура» – гарәп сүзе (табигат-ун) сүзеннән.

«Үзеңә кул салуның нәтиҗәсе» вәгазеннән өзек:

Хөрмәтле дусты, адәм баласының дөньяга тууы Аллаһның тәкъдире булән булган кебек аның дөньядан китүе дә Аллаһның фәрманы беләң булырга тиеш. Хаксыз, тиешсез бер кеше дә башкаларның һәм үзенең җанын коерга тиеш түгел. Пәйгамбәребез (с.г.в.) башка хәдисләрендә: «Хаксыз үзенә кул салган яки башкаларны үтергән кеше кабердә һәм ахирәт дөньясында тел белән аңлатып бирә алмаслык дәрәҗәдә каты газапларга дучар булачак», – дип әйтә [6, с. 64].

Тәкъдир «судьба, предопределение» – гарәп сүзе (тәкъдир-үн) «язмыш» сүзеннән.

Хак «истинный, настоящий, право» – гарәп сүзе (хакк) «туры, чын, дөрес» сүзеннән.

Җан «душа» – фарсы сүзе

(җан) «җан, энергия, тын, сулыш» бор. ирани. dah, dayah «тын, сулыш, һава» сүзеннән.

Хәдис «рассказ, предание, хадис (слова, приписываемые пророку Мухаммеду)» – гарәп сүзе (хәдис-ун) «Мөхәммәт пәйгамбәр сөйләгән сүзләр, сөйләмнәр» сүзеннән.

Кабер «могила» – гарәп сүзе (кабр) сүзеннән.

Ахирәт «загробная жизнь, верный друг» – гарәп сүзе (ахирәт-үн) «теге дөнья» сүзеннән.

Дәрәҗә «степень; чин, занимаемая должность» – гарәп сүзе (дәрәҗәт-ун) «мәртәбә, тоткан урын» сүзеннән.

Газап «мука, страдание» – гарәп сүзе (газаб-ун) «җәфа, җәза» сүзеннән.

«Аллаһтан курку хисләре» вәгазеннән өзек:

Әдеге кеше үлеп киткәннән соң, уллары аталарының васыятын үтәп, аның җәсәден утта яндырдылар, калаган тузан бөртекләрен җилгә очырдылар. Кыямәт көне килеп җиткәннән соң, Аллаһы Тәгалә: «Әй җир, шушы кешенең бөтен калдыкларын җый, аны кеше сурәтенә китер», – дип җиргә боерык бирер һәм җир аның төрле якка очып таралган барлык калдыкларын җыяр [6, с. 66-67].

Васыять «завещание, завет, воля, распоряжение» – гарәп сүзе (васыят-ун) «берәүнең үзе үлгәч үтәргә кушып калдырган эшләре» сүзеннән.

Җәсәд «тело, плоть» – гарәп сүзе (җәсәд-ун) «гәүдә» сүзеннән.

Кыямәт «воскресение, конец света» – гарәп сүзе (кыямәт-ун) «дини Ахирәт көне, дөнья беткән көн» сүзеннән.

Сурәт «картина, рисунок, вид, образ, форма, фигура» – гарәп сүзе (сурәт-ун) «рәсем, күренеш, кыяфәт, сын, килбәт» сүзеннән.

«Гөнаһлы кешеләргә ярдәм итү» вәгазеннән өзек:

Сәдака матур сүзне дә, төрле ярдәм итүләрне дә, Аллаһка шөкеранә кылуны да үз эченә ала. Аллаһы ризалыгы өчен берәр изгелек эшләү, әйтик, мохтаҗларга, ятимнәргә ярдәм кулы сузу, дусларга, күршеләргә игелек итү – болар барысы да кешенең үзенә игелек булып әйләнеп кайта торган гамәлләр. Бу хакта язылган китаплар, вәгазьләр шактый. Әмма югарыдагы сөйләгән риваятьтә гаҗәеп бер мәгънә бар, ягъни, анда гөнаһлы кешеләргә ярдәм итү турында сүз бара [6, с. 89].

Сәдака «милостыня, подояние» – гарәп сүзе (сәдакә-ун) сүзеннән.

Шөкер «благодарение, благодарность, признательность» – гарәп сүзе (шукур) «ризалык, канәгатьләнгәнлек күрсәтү» сүзеннән.

Риза «довольство, удовлетворение; согласие, подчине-

ние» – гарәп сүзе (рида-ан) «разыйлык, разый булу; карышмау, буйсыну» сүзеннән.

Мохтаҗ «нуждающийся, ощущающий потребность» – гарәп сүзе (мухтаҗ-ун) «хаҗәте булган кеше, фәкыйрь, ярдәмчесез» сүзеннән.

Ятим «сирота» – гарәп сүзе (йәтим-ун) «үксез ир бала» сүзеннән.

Гамәл «занятие, дело, действие, практика» – гарәп сүзе (гамәл-ун) «эш, йомыш, хәрәкәт» сүзеннән.

Китап «книга» – гарәп сүзе (китаб-үн) «китап» сүзеннән, гарәптә катаба «язу» тамырыннан, шуннан ук мәктәп, иск. мәктәб «хат», кятиб «секретарь».

Вәгазь «увещевание, проповедь» – гарәп сүзе (вәгаз-ун) «вәгазь, үгетләп, димләп, өндәп» сөйләнгән сүз.

Риваять «рассказ, повесть, легенда, роман, версия» – гарәп сүзе (риваят-ун) «берәр хәбәр яки сүзне икенче бер кешедән күчереп сөйләү; роман, хикәя» сүзеннән.

Мәгънә «значение, смысл, сущность, суть» – гарәп сүзе (мәгънә) «аңлашылган нәрсә; мәгънә, фикер, идея» сүзеннән.

Ягъни «то есть, значит» – гарәп сүзе (ягъни) сүзеннән.

Гөнаһ «грех» – фарсы сүзе (гүнаһ) «бурыч, гаеп, җинаять» сүзеннән. Тамыры бор.иран nā «гаеп, явызлык, хата, ялгыш».

Шулай итеп, беричә вәгазь мисалында шундый нәтиҗәгә килдек. Гарәп алынмалары ешрак кулланыла. Ягъни, без караган барлык алынмаларның 81% гарәп, 19% фарсы алынмалары.

Күргәнебезчә, вәгазь текстларында гәрәп-фарсы алынмалары шактый күп. Шулай итеп, телнең лексикасы үсә барганга күрә, кешеләрнең фикерләре бер-берсенә ныграк һәм ачыграк итеп аңлату өчен, аның мөмкинлекләре артканнан-арта барган. Башка телләрдәге шикелле үк, хәзерге татар әдәби телендә дә чит телләрдән кергән сүзләр сүзлек составының шактый өлешен тәшкил итәләр. Татар теленең лексик системасында гарәп катламы төрки-татар халкының мөселман дөньясы белән озак гасырларга сузылган аралашуы нәтиҗәсендә формалашкан, ул халкыбыз тарихының аерылгысыз өлеше булып тора. Лексик системаның бер катламы булган гарәби чыгышлы сүзләрдә милләтнең рухи мәдәнияте, эстетик дөньясы чагыла.

Әдәбият:

1. Әхмәтьянов Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимоллгик сүзлеге / Р.Әхмәтьянов. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2001. – 270 б.

2. Махмутов М.И. Гарапчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге / М.И. Махмутов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллина. – Казан: Иман, 1993. – 853 б.

3. Мөбарәк Җ. Хәтер дәфтәре / Җ. Мөбәрәк. – Казан: Дом печати, 2002. –287 б.

4. Нурмухаметова Р.С. Татар теле лексикасының эчке ресурслар хисабына үсеше (XX гасырның беренче яртысы) вестник ТГГПУ. – 2007. – №4 (11). – 6 б.

5. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология: югары уку йорты студентлары өчен. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.

6. ШәрәфетдинМ. Бәхетлеләрнеңсерләре/М. Шәрәфетдин. – Казан. 2013. – 129 б.

7. Электрон дәреслек / Югары уку йортлары өчен татар теле әсбабы (татар теле студентлар өчен) 2008. /.http://belem.ru/tatar-tele/vuz-tat/5.html /.